КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 апрель г.Казань № 366

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру хакында» 2013 ел, 29 июнь, 449 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 гыйнвар, 11 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау өчен кертемнәр исәбеннән җыелган акчаны максатчан файдалану һәм бу акчаның сакланышын тәэмин итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибенә, 4 пунктның икенче абзацында «республика дәүләт торак күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасын төзү турында» 2013 ел, 10 июнь, 394 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы уставына, 6.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин